ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.06.2018 492

Нурлат муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында” 2018 елның 31 нче маендагы 412 нче карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Түбәндә тәкъдим ителгән:

-Нурлат муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәне;

-Нурлат муниципаль районы мәктәпкәчә белем оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәне;

-Нурлат муниципаль районы өстәмә белем оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәне расларга.

2.Нурлат муниципаль районы мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең әлеге карарның 1 нче пункты нигезендә билгеләнгән хезмәт хакы, вазыйфаи бурычларның күләмен саклау шарты үтәлгәндә һәм хезмәткәрләр тарафыннан шул ук дәрәҗәдә эш башкарылганда хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнгән хезмәт хакыннан ким булырга тиеш түгел дип билгеләргә.

3.Нурлат муниципаль районы белем бирү оешмалары җитәкчеләренә, мәгариф хезмәткәрләренең профсоюз оешмасы белән килешү нигезендә:

-Нурлат муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган коллектив шартнамә, килешүләр, локаль норматив актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә;

-Нурлат муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүдә әһәмиятле үзгәрешләр кертүгә кимендә ике ай кала, әлеге карар нигезендә расланган хезмәт өчен түләүдә гамәлдәге үзгәрешләр хакында хәбәр итәргә.

4.Әлеге карарның 1 нче пункты 2018 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.С. Әхмәтшин

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренена хезмәт өчен түләү шартлары турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.Бу Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) хезмәткәрләрнең окладларын, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләре күләмнәрен һәм шартларын, шулай ук аларны билгеләү критерийларын формалаштыру тәртибен билгели.

2.Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:
хезмәт өчен түләү системасы - Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен, база окладлары (база вазыйфаи окладлары, эш хакының база ставкалары), окладлар (вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары) күләмнәрен кертеп, шулай ук федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгели торган нормалар җыелмасы;

база оклады – оешма хезмәткәренең 1 календарь ай буена яки хезмәт нормасы буенча вазыйфаларын үтәгән өчен, компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча куелган эш хакының база ставкасы (педагогик эшнең 1 атналык (1 еллык) эш хакы ставкасына караган сәгатьләр саны);

оклад (вазыйфаи оклад) – календарь аенда билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен, компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча хезмәт өчен түләүнең билгеләп куелган күләме;

эш хакы (хезмәткәр хезмәте өчен түләү) – башкарыла торган эшнең квалификациясенә, катлаулылыгына, санына, сыйфатына һәм шартларына бәйле булган хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре;

компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәлмәләр һәм өстәмә түләүләр, шул исәптән нормаль шартлардан тайпыла торган эш өчен һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр – стимуллаштыру характерындагы өстәлмәләр һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка бүләкләү белән бәйле түләүләр.

3.Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары вазифалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең (алга таба – мәгариф хезмәткәрләре) эш хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:
вазыйфаи окладлардан;
компенсация характерындагы түләүләрдән;
стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән.

4.Вазыйфаи эш стажы арту белән, белем алу яки белем алу турында документларны торгызу, квалификацион категория бирелү, мактаулы исем, ведомство бүләкләре бирелү белән бәйле эш хакы күләмен арттырырга хокук бирә

торган чор тулысынча хезмәт хакы сакланган түләүле еллык яки башка төрле ял, вакытлыча эшкә яраксыз булу чорына туры килгәндә, эш хакы күләмен үзгәртү шул чор тәмамланган көннәрдән соң гамәлгә куела.

5.Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре:

мәгариф хезмәткәрләренең эш хакы күләмен (вазыйфаи оклад) билгели торган белем турындагы, педагогик эш стажын раслаучы (билгеле бер вазыйфада белгечлек буенча эшләү) документларны һәм башка дәлилләрне тикшерәләр;

һәр ел саен гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең тарификацион исемлеген төзиләр һәм раслыйлар;

гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренә дөрес итеп һәм үз вакытында хезмәт хакы күләмнәре билгеләнүе өчен җавап бирәләр.

6. Гомуми белем бирү оешмаларын гамәлгә куючылар тарафыннан:

һәр ел саен уку ел башында мәгариф оешмалары җитәкчеләренең вазыйфаи оклады раслана;

гомуми белем бирү оешмасы җитәкчеләренең эшчәнлек алып бару нәтиҗәлелеге бәяләнеп, аларга шуның нигезендә стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгеләнә.